**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены карары**

**12.11.2024** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар , ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025елда үзарасалымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертүгә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
-Үзәк урамындагы юлга асфальт салу.

2.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.